**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 29 июлендәге 3155 номерлы карары**

**Казан шәһәре Совет районының**
**Родина урамындагы җир кишәрлекләренә**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

1.1.1. йогынты ясала торган мәйдан – 1521 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:060202:464, 16:50:060202:462;
- урнашу урыны: Родина урамы, Совет районы, Казан шәһәре;
- билгеләү максаты: 16:50:060202:467 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнаштыру планлаштырыла торган мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе территориясенә җәяү яисә транспортта керү;
- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән;

1.2. гариза бирүче: «Капитал Эстейт махсуслаштырылган төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы «Родина, Даурия, Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында»гы карары.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре


Башкарма комитетының

2024 елның 29 июлендәге

3155 номерлы карарына

1 номерлы кушымта

**16:50:060202:462, 16:50:060202:464 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:1500

| | |
|---|---|
| Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:060202 | кадастр кварталы |
| 16:50:060202:462, 16:50:060202:464 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________